Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Арча районы буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Арча районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БYЛЕК
ОБЩИЙ

Р. Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 16 июне
№ 28-ТРЗ

«Татарстан Республикасы
Арча районы буенча Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының суд участоклары
чикләре турында» Татарстан Республикасы
Законына кушымта

**Татарстан Республикасы**

**Арча районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

## 1 нче суд участогы

1 нче суд участогы чигенә «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең төньяк-көнчыгыш чиге белән Казансу елгасы кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, уң як ярны кертеп, Казансу елгасы үзәне буйлап көньяк-көнбатышка таба Казансу елгасының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнбатыш чиге белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап төньякка таба «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең төньяк-көнчыгыш чиге белән Казансу елгасы кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Арча муниципаль районының Апаз, Яңа Кенәр, Носы, Иске Ашыт, Иске Кырлай, Сөрде, Ташкичү, Шурабаш, Шушмабаш авыл җирлекләре.

## 2 нче суд участогы

2 нче суд участогы чигенә «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең төньяк-көнчыгыш чиге белән Казансу елгасы кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, сул як ярны кертеп, Казансу елгасы үзәне буйлап көньяк-көнбатышка таба Казансу елгасы белән «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнбатыш чиге кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнчыгышка таба «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең төньяк-көнчыгыш чиге белән Казансу елгасы кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Арча муниципаль районының Венета, Казанбаш, Кәче, Кушлавыч, Күпербаш, Наласа, Яңа Кишет, Яңа Кырлай, Сеҗе, Сикертән, Курса-

Почмак, Урта Аты, Урта Курса, Урта Пошалым, Иске Чүриле, Үрнәк, Утар Аты, Өчиле, Яңасала авыл җирлекләре.